**К.С.Фатхуллова, Ф.Р.Сибгаева**
*Казанский Приволжский (федеральный) университет*

## Татар телен укытуда заманча юнәлешләр

*татарский язык, коммуникативный подход, содержание обучения, средство общения*

Бүгенге көндә татар телен укытуда заманча юнәлешләрне куллану һәм дәресләрне гамәли эшчәнлеккә юнәлтү зарур. Телне шәхесара һәм мәдәниятара аралашу чарасы буларак укыту өчен, укытучыга түбәндәге принципларга нигезләнеп эш итү сорала: коммуникативлык принцибы (телне өйрәтү шартларын тормышта телне куллану шартларына якынайту); индивидуальләштерү принцибы (укыту процессын укучыларның шәхси ихтыяҗларын, индивидуаль-психологик үзенчәлекләрен исәпкә алып оештыру); телне актив фикерләү нигезендә үзләштерү принцибы (аралашу бурычына тәңгәл килгән тел берәмлекләрен мөстәкыйль куллана алу); тел һәм сөйләм материалын сайлауга һәм өйрәтүгә функциональ якын килү принцибы (материалның коммуникатив максаттан һәм кулланылыш ешлыгыннан чыгып билгеләнүе). Хәзерге шартларда татар теле укытучыларының төп бурычы – иҗади фикерләүче, иҗтимагый тормышта актив катнашучы, белемле полилингваль шәхес тәрбияләү. Шуңа бәйле рәвештә гамәлдә кулланыла торган заманча укыту юнәлешләренең төп методик эчтәлеге түбәндәгеләрдән гыйбарәт: 1) танып белүнең актив формаларыннан файдалану (модельләштерү, чагыштыру, системалаштыру, гомумиләштерү, анализлау, күзәтү ясау); 2) рефлексия (гомуми яки индивидуаль) өчен шартлар булдыру (куелган максаттан чыгып, эшчәнлекнең нәтиҗәләренә үзбәя бирә белү) [Фәтхуллова 2016: 48]. Гомуми белем бирүнең һәр баскычында укучыларда аралашу осталыгы (коммуникатив компетенция) булдыру мөһим. Аның берничә төренә төп игътибар бирү таләп ителә: сөйләм компетенциясе; тел компетенциясе; социаль-мәдәни компетенция; компенсатор компетенция. Укучылар әлеге осталыкларга ия булсыннар һәм телне гамәли үзләштерсеннәр өчен, билгеле бер биремнәр системасыннан эзлекле файдалана белергә кирәк. Алга таба әлеге осталыкларның һәр төренә аңлатма биреп һәм аларга бәйле эш төрләренә тукталып үтик.

Сөйләм компетенциясе – коммуникатив максатка ирешү өчен, телдән (диалогик һәм монологик) һәм язма сөйләм оештыра алу осталыгы ул. Сөйләмнең беренче формасы – диалогик сөйләмгә өйрәтүне укытучы, яңа таләпләрдән чыгып, дөрес оештыра белергә тиеш. Сыйныфтан сыйныфка укучыларда коммуникатив күнекмәләр булдыру эшен системалы рәвештә алып бару сорала: тәкъдим ителгән ситуация буенча әңгәмә кору яки сөйләшү үткәрү; полилогта катнашу; сөйләшүне башлап һәм кирәк очракта җанландырып җибәрү; үзеңне кызыксындырган

сорауларны бирү һәм аларга җавап алу һ.б. Укытучы, укучыларның диалогик сөйләмен бәяләгәндә, билгеле бер критерийларга таянып эш итә: аралашу максатына ирешүе; репликаларның лексик-грамматик яктан дөрес булуы; этикет үрнәкләрен урынлы куллануы; актив һәм итагатьле әңгәмәдәш булуы. Монологик сөйләмгә өйрәтү түбәндәгеләрне үз эченә ала: тема белән танышу; биремдә күрсәтелгән сорауларны яктыртып сөйләү; темага бәйле өстәмә сорауларга киңәйтелгән җаваплар бирү. Укучыларның монологик сөйләмен бәяләү критерийлары: коммуникатив максатка ирешүе; теманы тулысынча ачып бирүе; бәйләнешле сөйләмне лексик-грамматик яктан дөрес оештыруы. Укучыларда телдән һәм язма сөйләм осталыгы булдыру өчен, мәктәп дәреслекләрендә түбәндәге күнегүләр тәкъдим ителә: *Җөмләләрне укыгыз һәм сораулар куегыз; Диалогны тулыландырыгыз; Ситуациягә бәйле репликаны әйтегез; Телләр өйрәнү турында сөйләгез. Сөйләмегездә түбәндәге мәгълүматлар да булсын: мәктәптә телләр өйрәнү; татар теле дәресләре; телләр белүнең файдасы; Дустыгызның сорауларына җавап биреп, аңа хат языгыз; танылган шәхестән интервью алу өчен, сораулар төзеп языгыз; яшьләрне борчыган темага ток-шоу үткәрегез; Татарстанның югары уку йортлары турында Интернеттан мәгълүмат табыгыз һәм күмәк сөйләшү үткәрегез һ.б.* Иҗади эшләүче укытучы, шундый биремнәрне тагын да төрләндереп, укучыларның яшь һәм индивидуаль үзенчәлекләрен исәпкә алып эш итә. Моның өчен ул өстәмә чыганаклардан, уку әсбапларыннан файдалана ала. Соңгы елларда басылып чыккан кулланмаларда укучыларның сөйләм күнекмәләрен үстерү эшен яңача оештыру алымнары тәкъдим ителгән.

Тел компетенциясе – аралашу барышында тел берәмлекләрен дөрес куллана белү осталыгы ул, ягъни икенче телдә лингвистик кодка ия булу. Укучылар әлеге осталыкка ия булсыннар өчен, дәресләрдә махсус биремнәрне куллану зарур: *Кирәкле сүзләрне куеп, текстны укыгыз; Сүзләрне кирәкле формада куеп, текстны языгыз; Сүзләрдән җөмләләр төзеп әйтегез; Текстны укыгыз һәм туры килгән сүзне билгеләгез; Беренче җөмләнең эчтәлегенә туры китереп, икенче җөмләне язып бетерегез; Җөмләләрне дәвам итеп языгыз һ.б.* Мисаллардан күренгәнчә, мондый төр күнегүләр укучыларның лексик-грамматик күнекмәләрен үстерүгә, тел берәмлекләрен сөйләмдә дөрес куллана белүгә юнәлтелгән.

Социаль-мәдәни компетенция – икенче телдә сөйләшүче халыкның милли-мәдәни үзенчәлекләрен, сөйләм этикетын исәпкә алып, аралашу оештыра алу осталыгы ул. Татар теле дәресләрендә укытучы, белем бирү белән генә чикләнмичә, укучыларгга әхлакый тәрбия бирә, аларны аралашу барышында итагатьле әңгәмәдәш булырга өйрәтә. Моның өчен шундый күнегүләрдән файдаланырга мөмкин: *Итагатьле сүзләрне (сөйләм гыйбарәләрен) кулланып, әңгәмә корыгыз; Милли бәйрәмнәр турында сөйләшү үткәрегез; Халыклар дуслыгы турында проект эшен*

*башкарыгыз; ”Шәһәребезнең бер һәйкәле” темасына презентация әзерләп сөйләгез; Кыска диалогларны тыңлагыз. Вакыйгаларның кайда баруын билгеләгез; Ике дусның сөйләшүен тыңлагыз. Туры килгән җавапны билгеләгез h.б.* Алар ярдәмендә укучылар татар халкының гореф-гадәтләре, күренекле шәхесләре, татар мәдәнияте, сәнгате турында мәгълүмат алалар, ә болай эшләү, үз чиратында , аларны рухи яктан тагын да баета.

Компенсатор компетенция – икенче телдә аралашу барышында тел “кытлыгын” җиңеп чыгу осталыгы ул. Татар телен өйрәнгәндә, мондый күнекмәләргә ия булу шактый әһәмиятле, шуңа күрә укытучы дәресләрдә әлеге күнегүләрне актив кулланырга тиеш дип саныйбыз: *Контексттан чыгып, сүзләрнең мәгънәсенә төшенегез; Сүзнең мәгънәсен тамырыннан һәм кушымчаларыннан чыгып билгеләгез; Җөмләне кыскартып, фикерегезне белдерегез; Сөйләшү барышында әңгәмәдәшегездән ярдәм сорагыз; Бер үк фикерне төрле тел бәремлекләре белән белдерегез h.б.*

Санап чыккан осталыклар һәм аларны булдыруга юнәлтелгән эш төрләре укучыларның бәйләнешле сөйләм күнекмәләрен үстерү һәм лексик-грамматик белемнәрен тирәнәйтүгә, көндәлек тормыш, уку һәм кызыксынулар, дөнья яңалыклары турында хәбәр итәргә һәм фикер алышырга өйрәтүгә хезмәт итә. Алар ярдәмендә укучы үз эшчәнлеген нәтиҗәле оештырырга өйрәнә: коллектив аралашуда катнаша ала (төркемдә, парлап); индивидуаль җавап бирә ала; мисаллар китерә һәм үз фикерен дәлилли; күзәтүләр ясый һәм әйтелгәннәрне гомумиләштерә; үзләштергән мәгълүматны сөйләмдә куллана; чагыштыра һәм анализлый; үзтикшерү белән шөгыльләнә; дөрес җавапны сайлый, хаталарын төзәтә; нәтиҗәләр ясый һәм үзбәя бирә.

**Әдәбият**


Фәтхуллова К.С. Заманча дәрес – сыйфатлы белем нигезе / К.С.Фәтхуллова // Мәгариф, 2016. – №8. – Б. 48–51.

Федеральный государственный образовательный стандарт основного общего образования. – URL: edu.ru (дата обращения: 10.08.2018).

Языки в системе образования Республики Татарстан: по материалам этносоциологического исследования / Р.Н.Мусина и др. – Казань: Татар. кн. изд., 2011. – 158 с.